СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д.53,
с. Ерыклы,423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы,423185

тел.,факс.:(8-84348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

КАРАР КАРАР

2020 елның «28» октябреннән № 1

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылы 2021елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Зирекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22, 81 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. 2020 елның 21 ноябрендә сәгать 10 да 00 минутта, Яңа урам, 24 йорт адресы буенча урнашкан Өргәнче авыл клубында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылында 2021 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенының оештыру һәм үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.
3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Өргәнче авылы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- - юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- җәйге чорда территориядәне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/

бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлегенең Өргәнче авылының мәгълүмат стендында урнаштырырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге Башлыгы Җ.Г. Гайфетдинов